Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Клементейкино авыл Советы

КАРАРЫ

26 май 2022 ел | № 42

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2014 елның 5 ноябрендә кабул ителгән 129 номерлы “Клементейкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Клементейкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 1 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Клементейкино авыл Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Республикасы Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авыл Советының 2014 елның 5 ноябрендә кабул ителгән 129 номерлы «Клементейкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре, шулай ук Клементейкино авыл башкарма комитетында муниципаль хезмәткәрләрнең керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында нигезләмә хакында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

6 пунктның в) пунктчасында «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга;

13 пунктта «акцияләрен» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Клементейкино ав., Үзәк ур., 38 А йорт, Яңа Чишмә ав., Гафиатуллин ур., 3А йорт, Багряж ав., Кызыл Йолдыз ур., 38 А йорт торак пунктлар территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU), «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Клементейкино
авыл җирлеге башлыгы | Л.Э. Языков